ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

П О С Т А Н О В Л Е Н И Е　　　　　　　　　К А Р А Р

«07» август 2019 ел　　　　　　　　　№ 1106

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2015 елның 11 ноябрендәге 942 номерлы карары белән расланган Лениногорск муниципаль районы Шөгер авыл җирлегенең су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу схемасына үзгәрешләр кертү турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу схемалары турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 5 сентябрендәге 782 номерлы карарына («Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу схемаларын эшләү һәм раслау кагыйдәләре», «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу схемаларын карап тотуга таләпләр» белән бергә) таянып, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2015 елның 11 ноябрендәге 942 номерлы карары белән расланган Лениногорск муниципаль районы Шөгер авыл җирлегенең су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу схемасына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 бүлекнең 28 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ташландык суларны агызуның технологик зонасы» - юынтык суларны агызу үзәкләштерелгән системаның бер өлеше (канализация), юынтык суларны су объектына юынтык суларны агызу өчен билгеләнгән (су объектына юынты суларны агызу өчен) инженер корылмасына яисә юынтык суларны агызу өчен билгеләнгән берничә технологик бәйләнешле инженерлык корылмасына бүлеп бирү (су объектына юынты суларны агызып чыгару)»;

9 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бүлек 9. Үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларын үстерү күрсәткечләренең пландагы мәгънәләре»;

1 абзацта «максатчан» сүзен төшереп калдырырга;

9 бүлекнең беренче абзацы подпунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) суның сыйфаты күрсәткечләре;

б) су белән тәэмин итүнең ышанычлылыгы һәм өзлексезлеге күрсәткечләре;

в) ресурслардан файдалануның нәтиҗәлелек күрсәткечләре, шул исәптән суны югалту дәрәҗәсе (кайнар су составында җылылык энергиясе);

г) торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә дәүләт сәясәтен көйләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән башка күрсәткечләр».

2.Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Лениногорск муниципаль районы Шөгер авыл җирлеге башлыгына әлеге карарны Шөгер авыл җирлеге стендында игълан итәргә тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Җитәкче Н.Р. Залаков

Р.Р. Фарукшина
5-18-52